Мин татарча сөйләшәм!

# Мин татарча сөйләшәм!

Югары Ослан урта мәктәбе

*Безнең мәктәп берничә ел рәттән “Мин татарча сөйләшәм!” акциясендә бик теләп катнаша. Акциянең төп максаты – халыкны, бигрәк тә яшьләрне татар телендә сөйләшергә өндәү, кибетләрдә, урамда, китапханәләрдә һәм төрле көнкүреш хезмәтләре күрсәтә торган җирләрдә татарча сөйләшүне гамәлгә кертү, татар теленең даирәсен киңәйтү. Укучыларда татар телен дәүләт теле буларак өйрәнүгә кызыксыну уяту, талантлы яшьләрне барлау, иҗади фикер йөртү сәләтен үстерү, милли үзаң тәрбияләү. Сезгә үзебез үткәргән чараларның фотоотчётын җибәрәбез.*




“Мин татарча сөйләшәм” акциясе Югары Ослан мәктәбендә уку елы башыннан старт ала. Укучылар татар телендә уздырылган төрле чараларда, семинарларда, ачык дәресләрдә, түгәрәк өстәлләрдә актив катнашалар



Без татарча сөйләшәбез! Татар теле - безнең туган телебез! Үз теленнән йөз чөерүчеләрне, ана телләреннән ваз кичүчеләрне без аңламыйбыз. Әйдәгез, туган телебезне саклыйк, яклыйк, яратыйк!





**Туган телгә мәхәббәт аның бөек шәхесләре үрнәгендә дә уятыла. Мәктәбебездә Г.Тукайга, М. Җәлилгә.**











**Халыкара туган тел көненә багышлап мәктәп укучылары бик матур чыгыш ясадылар .**





**Безнең укучылар өлкәннәр йортында бик еш кунакта булалар**

Мәктәбебездә
“МИН ТАТАРЧА
СӨЙЛӘШӘМ!”
акциясенә багышланган
тел бәйгесе уздырылды






# Мәктәбебездә рус милләтеннән булган күп кенә укытучылар татар телен бик яратып өйрәнәләр



*“Мин татарча сөйләшәм” акциясе кысаларында укучылар Ослан урамнарына, җәмәгать урыннарына юл тоттылар. Изге сәфәребез мәктәп ишек төбеннән башланды.*



# Китапханәдә...








# Ашханәдә...



# Ослан урамы буйлап



# Укучылар сәүдә үзәкләрендә






# Даруханәдә



ОТДЕЛ ЛЬГОТНОГО
ЛЕКАРСТВЕННОГО
ОБЕСПЕЧЕНИЯ
VISA
ALERANA

# Мин татарча сөйләшәм



# Туган телемә

Р.Миңнуллин

Асыл сүзләреңне, туган телем,
Биреп торчы миңа азга гына.
Бөтенләйгә түгел – вакытлыча,
Тик җитәрлек гомер азагыма.
Синнән алган һәрбер сүземне мин
Күз карасы төсле саклар идем.
Ул сүзләрнең затлыларын сайлап,
Дога итеп кенә ятлар идем.
Ул сүзләрне җырга әйләндергәч,
Мин кайтарып сиңа бирәчәкмен.
Исраф ул сүзләрнең миндә,
Җыры булыр алар киләчәкнең.
Әйтә алмыйм әле – ул сүзләрдән
Аз булса да дөнья үзгәрерме?
Тик югалтмам, туган телем, синнән
Алып торган асыл сүзләремне.

“Мин татарча сөйләшәм!” акциясендә мәктәп укытучылары, укучылары һәм Ослан авылы халкы: сатучылар һәм сатып алучылар, үтеп баручылар, көнкүреш хезмәтен күрсәтүчеләр, машина йөртүчеләр һ.б. катнашты.

Акцияне оештыручылар: Югары Ослан мәктәбенең татар теле укытучылары Закирова Гөлнара Рифкат кызы, Корсак Суфия Фәйзулла кызы.

Ослан-2017 ел